**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**БАЙРАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАЙРАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422391, с. Байрашево, ул. Джалиля , 22

422391, Байраш авылы, Җәлил урамы, 22

тел. (84373) 57-5-13, факс 57-5-13, e-mail: Bay.Tet@tatar.ru

ОГРН 1061672020299, ИНН/КПП 1638005227/163801001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 2**

**11.03.2025**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 1743 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында " 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Байраш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ::

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген төзү һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыруның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.
2. Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенә 1 апрельгә кадәр Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге башкарма комитетына хисап елындагы һәм хисап елына кадәрге елдагы һәр салым чыгымы буенча белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:

- ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
- Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджетының төшеп кала торган керемнәре суммалары турында;
- һәр салым чыгымы буенча Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының Байраш авыл җирлеге бюджетына түләүчеләр тарафыннан декларацияләнгән салым күләмнәре турында.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://tetushi.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Җитәкче** А.М.Гобәев